# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Зур Полянка авыл җирлеге Зур Полянка авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 14 октябреннән** **№__1_**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 13 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Зур Полянка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) авыл эчендәге юлларны карап тоту;
2) авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
3) торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
4) су челтәрләрен реконструкцияләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 265 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 160 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 159 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 1 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлегендәге Зур Полянка авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны танырга: «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Зур Полянка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча

теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) авыл эчендәге юлларны карап тоту;

2) авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

3) торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;

4) су челтәрләрен реконструкцияләү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Зур Полянка авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы Н.И. Александрова